ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ РӘҖӘП АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАР

13 март 2020 ел №85-2

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Иске Рәҗәп авыл җирлеге Советының «Иске Рәҗәп авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында " 08.10.2009 ел, № 75-1 карары белән расланган Иске Рәҗәп авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында (24.01.2020, 83-3 номерлы үзгәрешләре белән)

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына казначылык хезмәте күрсәтү һәм казначылык түләүләре өлешендә үзгәрешләр кертү турында " 2019 елның 27 декабрендәге 479-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Иске Рәҗәп авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Иске Рәҗәп авыл җирлеге Советының «Иске Рәҗәп авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 08.10.2009 ел, № 75-1 карары белән расланган Иске Рәҗәп авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә (24.01.2020, 83-3 номерлы үзгәрешләре белән)

1.1. Нигезләмәнең 15 статьясындагы 15 абзацын үз көчен югалткан дип танырга.

1.2. 45 статьяның 3 пунктында «түләүле һәм» сүзләрен «казначылык түләүләрен башкару турында боерыклар (алга таба - боерык) һәм» сүзләренә алмаштырырга, «түләү документлары» сүзләрен «боерыклар» сүзенә алмаштырырга.

2. Әлеге карар 2021 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Иске Рәҗәп авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ www.spasskiy.tatarstan.ru), һәм хокукый мәгълүмат сайтында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Иске-Рәҗәп авыл җирлеге башлыгы М.Ә.Нугаев